КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 август г.Казань № 918

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 март, 151 нче; 2020 ел, 26 март, 221 нче; 2020 ел, 16 июнь, 496 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1004 нче; 2021 ел, 13 август, 712 нче; 2021 ел, 4 ноябрь, 1050 нче, 2022 ел, 14 март, 230 нчы, 2022 ел, 28 март, 279 нчы, 2022 ел, 30 сентябрь, 1052 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1491 нче, 2023 ел, 16 март, 258 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2018 елның 22 июнендәге ПУ-454 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

4 пунктта «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «тармак компетенциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

8 пунктчаның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктчада «дәүләт хакимиятенең тармак башкарма органнары» сүзләрен «башкарма хакимиятнең тармак республика органнары» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22) эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыра, шул исәптән һөнәрләр һәм һөнәри белем бирү белгечлекләре буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә тармаклар ихтыяҗының фаразын формалаштыра;»;

33 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

42 һәм 43 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга;

49 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

60 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тармак башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин